# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге составына керүче **Җәнлек совхозы** торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 4 «10» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең **Җәнлек совхозы** торак пунктында 2020 елның «10» ноябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге **Җәнлек совхозы** торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**- Урманчы авыл жирлегенен Җәнлек совхозы торак пунктында җирле әһәмияттәге юлларны чокырлар ремонтлау һәм грейдлау (сатып алу,ташу,вак таш җәю , килешү буенча эшләр өчен түләү)**

**- Урманчы авыл жирлегенен Җәнлек совхозы торак пунктында җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;**

**-Урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).**

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 609 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 323 кеше, 53,0% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 323 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең **Җәнлек совхозы** торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең **Җәнлек совхозы** торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге **Җәнлек совхозы** торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**- Урманчы авыл жирлегенен Җәнлек совхозы торак пунктында жирле әһәмияттәге юлларны чокырлар ремонтлау һәм грейдлау (сатып алу,ташу,вак таш җәю , килешү буенча эшләр өчен түләү)**

**- Урманчы авыл жирлегенен Җәнлек совхозы торак пунктында жирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;**

**-Урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).**

3. Әлеге карарны Урманчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе А.Я.Ильин